**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 454**
**03.10.2023**

Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законның 12, 13 статьялары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары (шәһәр Хакименең 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы, 2016 елның 1 февралендәге М 34 номерлы, 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы, 2021 елның 14 маендагы М 186 номерлы, 2022 елның 14 мартындагы М 94 номерлы, 2022 елның 17 июнендәге М 254 номерлы, 2022 елның2 ноябрендәге М 484 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы М 113 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәгә, 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«16. Муниципаль хезмәткә кергәндә, граждан тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук

хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәү, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, күрәләтә тулы булмаган мәгълүматлар бирелү яисә күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматлар бирелү әлеге гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Мондый мәгълүматларны бирү мәҗбүри булган очракта, муниципаль хезмәткәр тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәү яисә, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, күрәләтә тулы булмаган мәгълүматлар бирелү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге пунктның 2 абзацында күрсәтелгән күрәләтә дөрес булмаган мәгълүмат бирелү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев